СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

28.06.2024 № 47/8

На №__________ от______________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 36/5 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге сатулар үткәрмичә сатыла торган җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибе турында, Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмен билгеләү тәртибе хакында, Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектәге җир кишәрлекләре мәйданы арткан өчен түләү күләмен билгеләү тәртибе турында, Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләренә карата гавами сервитут билгеләү турында килешү буенча түләү күләмен билгеләү тәртибе хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 312-ФЗ номерлы Федераль закон, район уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 36/5 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге сатулар үткәрмичә сатыла торган җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибе турында, Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмен билгеләү тәртибе хакында, Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектәге җир кишәрлекләре мәйданы арткан өчен түләү күләмен билгеләү тәртибе турында, Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләренә карата гавами сервитут билгеләү турында килешү буенча түләү күләмен билгеләү тәртибе хакында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 1 кушымтаның 3 пункты 6 пунтчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарга шәхси торак төзелеше, торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару өчен, гражданнарга яки крестьян (фермер) хуҗалыкларына эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру өчен әлеге кодексның 39.18 статьясы нигезендә җир кишәрлекләре».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (https://tukay.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров